КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 апрель г.Казань № 286

Кайбер дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү һәм хезмәте өчен түләүне җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 август, 748 нче, 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы, 2022 ел,

15 сентябрь, 1005 нче, 2023 ел, 9 июнь, 703 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазифаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә учреждениеләр җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,05 тапкырга индекслаштырырга һәм аны 13 323 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе», «Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе каршындагы Кунак йорты» һәм «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениеләре эшчеләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 29 март, 194 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 август, 748 нче, 2021 ел, 7 декабрь, 1189 нчы, 2022 ел, 15 сентябрь, 1005 нче, 2023 ел, 9 июнь, 703 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «15 проценты» сүзләрен «37 проценты» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның 4 пунктчасында «15 проценты» сүзләрен «37 проценты» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Учреждениеләр җитәкчеләренә элегрәк чыгарылган актларын бу карарга туры китерергә.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин